МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.04.2021 г.Казань № 269

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 28 маенда 7694 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 20 июлендәге 585 номерлы боерыгы белән расланган Чернобыль АЭСында һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә вафат булган гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче вафат булган гражданнарны җирләүгә гаилә әгъзаларына яки җирләү оештыруны үз өстенә алган затларга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Чернобыль АЭСында һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә вафат булган гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче вафат булган гражданнарны җирләүгә гаилә әгъзаларына яки җирләү оештыруны үз өстенә алган затларга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 20 июлендәге 585 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 20.07.2015 №475, 07.06.2016 №317, 08.06.2017 №351, 27.11.2017 №835, 15.05.2018 №368, 18.09.2018 №883, 17.01.2019 №31, 16.04.2019 №276, 27.08.2019 №652, 12.11.2019 №984, 06.07.2020 №488,

08.10.2020 №711 боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Чернобыль АЭСында һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә вафат булган гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче вафат булган гражданнарны җирләүгә гаилә әгъзаларына яки җирләү оештыруны үз өстенә алган затларга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының 2021
елның 29 апрелендәге 269 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә үлгән гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче үлгән гражданнарны җирләүгә гаилә әгъзаларына яки җирләү оештыруны үз өстенә алган затларга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2012 елның 20 июлендәге 585 номерлы боерыгы белән расланган Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә үлгән гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче үлгән гражданнарны җирләүгә гаилә әгъзаларына яки җирләү оештыруны үз өстенә алган затларга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2.5 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының беренче абзацында «югарыда күрсәтелгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.6 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3.4.1 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3.4.2 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

3.8.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.8.1. Үзәк бүлекчәсе белгече:

техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы);

пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерә;

пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны имзалау өчен Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен юлланган пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Үзәк бүлекчәсенә, Үзәккә яки Министрлыкка кергән шикаять ул кергән көненнән соңгы икенче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.».